# Ярдәмче фигыльләр.

Фигыль дәрәҗәләре

Татар теле
Морфология

# Фигыль дәрәҗәләре.
# Ярдәмче фигыльләр.

# Фигыль дәрәҗәләре

*-эш-хәлнең үтәлү дәрәҗәсен белдерә;*

*-эш-хәлнең үтәлешенә башлану, тәмамлану, дәвамлылык, кинәтлек, кабатлану,  өлешчә генә үтәлүе кебек мәгънә төсмерләрен бирә;*

*-**ярдәмче фигыльләр (аналитик чаралар) һәм кушымчалар (синтетик чаралар) белән белдерелә.***

# Ярдәмче фигыльләр



*Марат урыныннан торды һәм укытучыга карап тора.*

**Сөйләмдә мөстәкыйль фигыльләр ярдәмче фигыль функциясен дә үти ала. Бу вакытта алар мөстәкыйль фигыльгә өстәмә мәгънә өсти.**

# Ит, икән, ит ярдәмче фигыльләре

(аерым гына кулланылмыйлар)



*Урамда кар ява иде.*



*Йолдызларны кем яндыра икән?*



*Кызым, миңа ярдәм ит!*

# Мөстәкыйль һәм ярдәмче фигыльләр



*Ул тоткан балыгын*
*кире елгага җибәрде.*



*Бала куркудан*
*елап җибәрде.*

**Фигыльләрнең кайчан мөстәкыйль, кайчан ярдәмче икәнлеге җөмләдә күренә.**

# Мөстәкыйль һәм ярдәмче фигыльләрнең кулланылышы



*Айсылу энесенә карады.*

*Айсылу энесенә рәсем ясады.*

**Мөстәкыйль фигыльләр төп мәгънәне белдерәләр.**

*Мин ясап карадым.*



*Син ясап карадың.*



*Без ясап карадык.*



**Ярдәмче фигыльләр зат-сан белән төрләнәләр.**

**Мөстәкыйль фигыльләр төп мәгънәне белдерәләр, ә ярдәмче фигыльләр зат-сан белән төрләнәләр.**

***Иде** ярдәмче фигыле:*

*1) үткән заман төсмере өсти: бәхетле иде, җидәү иде;*
*2) үткән заман хикәя фигыльнең катлаулы формаларын ясый: кайта иде, көткән иде;*
*3) теләк мәгънәсен белдерергә ярдәм итә: күрергә иде, барсаң иде.*